ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 407-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Т.Г. Һадиев, Ф.Ф. Баһаутдинов, Р.Ә. Сөләйманов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 407-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1905-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Т.Г. Һадиев,
Ф.Ф. Баһаутдинов,
Р.Ә. Сөләйманов
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 6 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр.»;

7 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр.»;

4) 8 статьяның 1 өлешендәге кырыгынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр.»;

5) 13 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 2017 елның 13 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе:»;

в) 3 пунктта «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнары» сүзләрен өстәргә;

2) 9 статьяның 1 пунктында «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнары» сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында әзерләнде.

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләрен билгели торган 94 статьясы яңа редакциядә бәян ителде. Күрсәтелгән статьяның 1 өлешендәге 23 пунктының яңа редакциясе нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары белән генә түгел, ә Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнары белән дә хезмәттәшлеген оештыра.

Закон проектында «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 2017 елның 13 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү һәм шундый ук рәвештә Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләрен төгәлләштерү, шулай ук күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләрен билгели торган 9 статьясына төгәлләштерә торган үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

Шулай ук закон проектында «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 2017 елның 13 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасы Экология кодексына Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасы исемен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү каралган.

Моннан тыш закон проектында Татарстан Республикасы Экология кодексына редакцион үзгәрешләр кертү, шулай ук аның 5 статьясындагы Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамәне искә алуны, әлеге Шартнамәнең гамәлдә булу чоры узуга бәйле рәвештә, төшереп калдыру өлешендә нигезләмәләрен төгәлләштерү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының башка законнарын һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итми.